| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ЗЕМЕЛЬНЫХ И<br>ИМУЩЕСТВЕННЫХ<br>ОТНОШЕНИЙ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ<br>ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ<br>МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

11.03.2026 Казан ш. 505-р

Газ бүлгеч газүткәргечнең саклау зонасын үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасының Бөгелмә, Азнакай, Лениногорск муниципаль районнары территориясендә бүлгеч челтәрләрнең саклау зонасы чикләрен билгеләү турында» 24.03.2020 № 962-р карарына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» ДБУ хатын исәпкә алып (10.03.2026 № 01А-04/713) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып:

1. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милке булган, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасының Бөгелмә, Азнакай, Лениногорск муниципаль районнары территориясендә бүлгеч челтәрләрнең саклау зонасы чикләрен билгеләү турында» 24.03.2020 № 962-р Карары (алга таба - № 962-р Карар) белән урнаштырылган

13068 инвентарь номерлы, 16:46-6.532 реестр номерлы бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасын ПРГ үзгәрү аркасында, трасса үзгәртелеп газүткәргеч үзгәртеп корылу сәбәпле территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, үзгәртергә. Бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасы озынлыгы гомуми мәйданы 63726 +/- 88 кв.м.лы территория рәвешендә 15931,5 м.ны тәшкил итә.

2. Инвентарь номеры 13068 булган газ бүлгеч газүткәргечне эксплуатацияләү срогында газ бүлү челтәрләре объектының саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлгеч челтәрләрне саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. Территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлеге нигезендә № 962-р Карарның 1 пунктына «гомуми мәйданы 3 002 013,945 кв.м.лы территорияне тәшкил иткән» сүзләрен «озынлыгы 750499,49 м.лы, гомуми мәйданы 3001997,95 кв.м. территорияне тәшкил иткән» сүзләре белән алмаштырып үзгәреш кертергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.Ә.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**